| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>БОЛЬШЕПОДБЕРЕЗИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ОЛЫ ПОДБЕРЕЗЬЕ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03 ноябрь, 2023 ел Олы Подберезье авылы № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Олы Подберезье авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы,Т атарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең Олы Подберезье торак пунктында ТР, Кайбыч районы, Олы Подберезье авылы, Ирек мәйданы, 31 нче йорт адресы буенча урнашкан Олы Подберезье авыл мәдәният йорты бинасында 2023 елның 20 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең Олы Подберезье торак пунктында ТР, Кайбыч районы, Олы Подберезье авылы, Ирек мәйданы ур., 11 нче йорт адресы буенча урнашкан Олы Подберезье урта мәктәбендә 2023 елның 21 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең Олы Подберезье торак пунктында ТР, Кайбыч районы, Олы Подберезье авылы, Калинин урамы адресы буенча урнашкан МТФ территориясендә 2023 елның 22 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең Олы Подберезье торак пунктында ТР, Кайбыч районы, Олы Подберезье авылы, Заводская урамы, 11 нче йорт янында 2023 елның 23 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының бишенче этабын билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең Олы Подберезье торак пунктында ТР, Кайбыч районы, Олы Подберезье авылы, Полевая урамы, 2 нче йорт янында 2023 елның 28 ноябрендә 16 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының бишенче этабын билгеләргә.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«2024 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Олы Подберезье торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаиләләренең балигъ булган әгъзаларыннан тыш даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәл әләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- янгын автомашинасын, җиһазларын, биналарын һәм ДЕПО эшчесенең тоту;
- авыл җирлеге торак пункты территориясен карап тоту;
- җирлек торак пункты чикләрендә автомобиль юлларын карап тору;
- территорияне торак пунктның Олы Подберезье санкцияләнмәгән чүплекләреннән чистарту;
- зират территориясен карап тору, төзекләндерү һәм ремонтлау, материаллар сатып алу;
- су үткәрү челтәрләрен ремонтлау, материаллар сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы

Кайбыч муниципаль районы

Олы Подберезье авыл җирлеге башлыгы О.М. Емельянова